Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXV-4**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 6 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балтач авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге 4 номерлы карары белән расланган Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, җирдән файдалану һәм төзелеш эшләрен җайга салу тәртибен камилләштерү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, 2022 елның 21 ноябрендә үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балтач авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге 4 номерлы карары белән расланган Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 31.03.2021 ел IX-22, 30.10.2021 ел XIII-4 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 25 маддәнең 2 өлешендәге 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“4) җир кишәрлегендә ярдәмче куллану төзелмәләре һәм корылмалары төзү, аларга кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;”;

1.2) 27 маддәнең 9 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“төзелеш этабы” – бер җир кишәрлегендә төзү, реконструкцияләү планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектлары исәбеннән капиталь төзелеш объектын төзү яки реконструкцияләү, әгәр мондый объект автоном рәвештә эксплуатациягә кертелергә һәм эксплуатацияләнергә (ягъни бу җир кишәрлегендә башка капиталь төзелеш объектларын төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә), капиталь төзелеш объектын төзү яисә реконструкцияләү, ул автоном

файдалануга кертелергә һәм эксплуатацияләнергә мөмкин булса (ягъни әлеге капиталь төзелеш объектының башка өлешләрен төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә), шулай ук капиталь төзелеш объектын урнаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләренә ия булу һәм алардан файдалану хокукларын рәсмиләштерүне үз эченә алган төзелеш территориясен әзерләү эшләре комплексы (капиталь төзелеш объекты өлешенең), биналарны, төзелмәләрне һәм корылмаларны сүтү, инженерлык коммуникацияләрен яңадан кору (күчерү), вакытлыча биналар һәм корылмалар төзү, урман кисү һәм башка эшләр.";

1.3) 36 маддәнең 11 өлешендәге 18 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Су объектының милекчесе суларның тискәре йогынтысын булдырмау һәм аның нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар күрергә тиеш. Федераль милектә булган су объектларына, Россия Федерациясе субъектлары милкенә, муниципаль берәмлекләр милкенә карата суларның тискәре йогынтысын булдырмау һәм аның нәтиҗәләрен бетерү чаралары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә һәм Россия Федерациясе Су кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.";

1.4) 36 маддәнең 8 өлешендәге 17 абзацында "туфракларның уңдырышлылыгын җайга салу" сүзләрен "туфракларның уңдырышлылыгын арттыру;" сүзләренә алмаштырырга;

1.5) 27 маддәнең 5 пунктының 6 пунктчасын ", Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 51 маддәсендәге 6.2 пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортны реконструкцияләү очракларыннан тыш, блокланган төзелешнең бер йортын реконструкцияләү очрагында, барлык йортларның да бер рәттә блокланган төзелешнең хокук ияләренең ризалыгы." сүзләре белән тулдыландырырга;

1.6) 30 маддәнең 6 пунктында "утыз көн" сүзләрен "егерме биш көн"сүзләре белән алыштырырга;

1.7) 16 маддәнең 1 пунктында "капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү" сүзләреннән соң "мондый рөхсәтнамә бирү турында гариза килгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә әзерләнә һәм" сүзләрен өстәргә;

1.8) 30 маддәнең 2 пунктындагы 2 абзацына түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

"-территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итү";

1.9) 30 маддәнең 3 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзацларны өстәргә:

"-Россия Федерациясе тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы яисә юридик зат тарафыннан (алга таба – Россия Федерациясе тарафыннан билгеләнгән юридик зат);

- Татарстан Республикасы төзегән һәм Татарстан Республикасы тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру максатларында территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзегән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы, Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органы, Татарстан Республикасы төзегән юридик зат йә территорияне комплекслы үстерү турында Татарстан

Республикасы кабул иткән карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче зат тарафыннан;”;

1.11) 36 маддәнең 7 пунктындагы 20 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “пестицидлар һәм агрохимикатлар саклау (агрохимикатларны диңгез портлары территорияләрендә махсус саклагычларда саклау полосалары чикләреннән тыш), пестицидлар һәм агрохимикатларны куллану;”;

1.11) 29 маддәнең 5 пунктында:

4 абзацны “,Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 маддәсендәге 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объектының мәйданы үзгәрү очракларыннан тыш” сүзләре белән тулыландырырга;

5 абзацка “проект документлары” сүзләреннән соң “,Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 маддәсендәге 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объектының мәйданы үзгәрү очракларыннан тыш” сүзләрен өстәргә;

1.10) 9 маддәнең 4 пунктында «җиде эш көне дәвамында» сүзләрен «биш эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

1.11) 26 маддәнең 7 пунктындагы 4-8 абзацларының үз көчләрен югалтуын танырга;

1.12) 32 маддәнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында территориаль зоналарның чикләре билгеләнә. Территориаль зоналар чикләре җир законнары нигезендә территориаль зоналар чикләрен узарга мөмкин булган җир кишәрлегеннән тыш, һәр җир кишәрлегенең бер территориаль зонага туры килү таләбенә җавап бирергә тиеш.”;

1.12) 15 маддәнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пунктын өстәргә:

“1.1. Җир кишәрлекләренә хокукчылар төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәтнамә өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы, әгәр мондый тайпылыш конкрет территориаль зона өчен шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын бер яисә берничә чикле параметрны бер мәртәбә үзгәртү, реконструкцияләү максатларында ун проценттан да артмаска тиеш булса.”;

1.13) 30 маддәнең 7 пунктындагы 34 нче абзацны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

“нефть һәм нефть продуктларының су объектларын һәм алар янындагы территорияләрне саклауны һәм әйләнә-тирә мохиткә башка тискәре йогынтыны тәэмин итә торган корылмалар.”;

1.13) 36 маддәнең 7 пунктындагы 31 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“автомобильләргә ягулык салу станцияләре, ягулык-майлау материаллары складлары, транспорт чараларын техник тикшерү һәм ремонтлау өчен кулланылган техник хезмәт күрсәтү станцияләре төзү һәм реконструкцияләү, транспорт чараларын юу (автомобильләргә ягулык салу станцияләре, ягулык-майлау материаллары складлары портлар, эчке су юллары инфраструктурасы территорияләрендә, шул исәптән кече судноләр кую өчен базалар (корылмалар), федераль иминлек хезмәте органнары объектларында урнаштырылган очраклардан тыш);”;

1.14) 28 мадданең 10 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

28 мадданең 9 пунктындагы 1 пунктчада күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларына карата дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметы булып түбәндәгеләрне үтәү тора:

1) капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү барышында башкарыла торган эшләрнең һәм кулланыла торган төзелеш материалларының һәм эшләнмәләренең, шулай ук мондый эшләрнең нәтиҗәләре Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсендәге 15, 15.2 һәм 15.3 өлешләре нигезендә расланган таләпләр нигезендә проект документациясенең туры килүе (шул исәптән эш документациясенә кертелгән һәм Шәһәр төзелеше кодексының 52 маддәсендәге 1.3 өлеше нигезендә мондый проект документациясенең бер өлеше булган үзгәрешләрне исәпкә алып) һәм (яисә) мәгълүмат моделенә (мәгълүмат моделен формалаштыру һәм алып бару Шәһәр төзелеше кодексы таләпләре нигезендә мәҗбүри булган очракта);

2) төзелешкә рөхсәтнамә булу таләпләре;

3) Шәһәр төзелеше кодексының 52 маддәсендәге 2 һәм 3.1 өлешләрендә билгеләнгән таләпләр;

4) Шәһәр төзелеше кодексының 52 маддәсендәге 4 өлешендә билгеләнгән таләпләр капиталь төзелеш объектын консервацияләүне тәэмин итүгә;

5) Шәһәр төзелеше кодексында, башка норматив хокукый актларда билгеләнгән төзелеш контролен гамәлгә ашыру тәртибенә таләпләр.

28 мадданең 9 пунктындагы 2 пунктчада күрсәтелгән объектларга карата дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметы булып түбәндәгеләрне үтәү тора:

1) төзелешкә рөхсәтнамә булу һәм капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәтнамәдә күрсәтелгән параметрларга туры килү таләпләре, әгәр капиталь төзелеш объектын төзү яисә реконструкцияләү өчен рөхсәтнамә таләп ителсә;

2) капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларына, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә туры килү һәм әгәр дә капиталь төзелеш объектын төзү яки реконструкцияләү өчен төзелеш рөхсәте кирәк булмаса, бу Кодекс, башка федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры килә.".

1.19) 29 мадданең 3 пунктындагы 9 пунктчада "проект документлары" сүзләреннән соң "(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.8 һәм 3.9 өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган проект документларын да кертеп)" сүзләрен өстәргә;

1.20) 28 мадданең 5 пунктында "Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә" сүзләрен "Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.8 һәм 3.9 өлешләрендә каралган тәртиптә." сүзләренә алыштырырга.

1.21) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең кадастр номеры

16:34:270302:422, мәйданы 43537 кв. м. булган җир кишәрлеген үз эченә алган яңа теркәлә торган редакциядә шәһәр төзелешен зоналаштыру картасын һәм территориядән файдалануның махсус шартлары булган картаны расларга, ул Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балтач авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, агросәнәгать комплексы объектларын һәм агросәнәгать комплексына хезмәт күрсәтү объектларын урнаштыру зонасын билгеләү өлешендә (СХ1).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балтач авылы, Татарстан урамы, 56А йорт һәм Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов

КАРТА ЗОН С ОСОБЫМИ УСЛОВИЯМИ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ ТЕРРИТОРИИ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ЮЛСУБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН



ПРАВИЛА ЗЕМЛЕПОЛЬЗОВАНИЯ И ЗАСТРОЙКИ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
"ЮЛСУБИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" РЫБНО СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ
КАРТА ГРАДОСТРОИТЕЛЬНОГО ЗОНИРОВАНИЯ

